| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ДЕВЯТЕРНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ДЕВӘТЕРНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.08. 2025 Девәтернә авылы № _10_

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 нче елның 02.09. кабул ителгән «Агачларны, куакларны, газонны кисү, формалаштыру һәм күчереп утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 14 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлеге территориясендәге Россия Федерациясе дәүләти урман фондына һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән яшел үсентеләрне кисү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында”гы 2021 елның 12 февралендә кабул ителгән 7-1 номерлы карарын, Әгерҗе районы прокуратурасының 11.03.2025 ел 02-08-01-2025/Прдп99-25-20920003/43 номерлы протестын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге башкарма комитеты карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлеге башкарма комитетының «Агачларны, куакларны, газонны кисү, формалаштыру һәм күчереп утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 02.09.2021 елда кабул ителгән 14 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1) 3.5.2.1 пунктының 7 абзацын, 3.5.2.2 пунктының 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлеге территориясендә киселә торган яшел үсентеләрнең һәм компенсацион яшелләндерү бәясен Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлеге

башкарма комитетының 25.08.2025 елның 9 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлеге территориясендә киселә торган яшел үсентеләрнең бәясен исәпләү методикасы нигезендә исәпләп чыгара”.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында бастырырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталы составында Әгерҗе муниципаль районының официаль сайтында https://agryz.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкчесе Э.Э. Ганиев